**Татар telendә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 60**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3** | **2** | **4** | **3** | **1** | **4** | **3** | **2** | **4** | **рәвеш** |

**II. Теоретик бирем.**

Сузык авазлар өлкәсендә очрый торган аваз үзгәрешләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз һәм андагы басымның урынын тәңгәллек белән күрсәтегез**,** җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| СҮЗ | БАСЫМ УРЫНЫ |
|---|---|
| А) пәрәмәч | 1) икенче иҗектә |
| Ә) бирешмәскә | 2) өченче иҗектә |
| Б) кайчаннан | 3) беренче иҗектә |
| В)  кырмыскалар | 4) дүртенче иҗектә |
| Г) чишелешендә | 5) бишенче иҗек |

**Җавап : 21345**

## IV. Гамәли-иҗади бирем

1. Мәкальләрнең ахырын  уйлап языгыз. **(5 балл)**
   *Егет сүзе* бер булыр.
   *Бер – алдыңа,* биш артыңа кара.
   *Аз сөйлә, күп эшлә.*
   *Җиде кат үлчә,* бер кат кис.
   *Туры әйткән – котылган,* ялганлаган – тотылган.
2. Текстны укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

Мин үзем икмәкне кеше өчен иң зарури ризык итеп кенә түгел, ә илнең иң зур байлыгы, дәүләтнең төп к**у**әте дип тә саныйм. Чыннан да, илдә, дәүләт кулында икмәк җитәрлек булмаса, халык тук, бөтен яши алыр идемени, дәүләт башка байлыкларын бүтән ихт**ы**яҗларга тота алыр идемени?..

Халык икмәкнең дәрәҗәсен кытлык елларда гына түгел, **һ**әрвакытта, иң уңган чакларында да бик яхшы белгән. Ул аны юкка-барга әрәм-шәрәм итмәгән, саклап тоткан, ничек тә запас белән торырга тырышкан.  Безнең татар халкында исә икмәккә хөрмәт аеруча зур иде. “Ипекәй” дип к**а**дерләп кенә йөртә иде ул аны... (*Әмирхан Еникидән*)

3. Текстта антонимик парлы сүзне күчереп языгыз. **(2 балл)**

**юкка-барга**

4. *Байлыкларын* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)
бай – тамыр, -лык – исем ясагыч кушымча, -лар – күплек сан кушымчасы, модаль, -ын –3 нче зат төшем килеше кушымчасы, бәйләгеч. Байлыкларын – ясалма исем, уртаклык исем, төшем килешендә, 3 зат тартым белән төрләнгән, күплек санда.
5. *"Ипекәй" дип кадерләп кенә йөртә иде ул аны*... җөмләсендәге сүзләрне туры тәртипкә куеп языгыз. **(2 балл)**
Ул аны "ипекәй" дип кадерләп кенә йөртә иде.
6. Тексттан рус алынмасын күчереп языгыз. **(2 балл)**
**запас**
7. *"Азның кадерен белмәгән күпнең кадерен белмәс"* темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)